Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

21 март 2019 ел № 10

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Әлмәт муниципаль районында һәм Әлмәт шәһәрендә халык алдында тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. «ТР, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ф.Кәрим урамында түбән басымлы газүткәргечне күчерү» объекты өчен территорияне планлаштыру проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 29 мартында 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң кимендә ике һәм өч айдан да артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4. Түбән басымлы газүткәргечне күчерү объекты өчен территорияне планлаштыру проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр “ Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе” муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 29 мартына кадәр.

3. “Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе” муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга

һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы А.Р. Хайруллин